| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.05.2026 ел № 232-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2008 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы указына туры китереп боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәр-ләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 26 июнендәге 222-осн номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлы-
гының 2026 елның ___________
№_____ боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 26 июнендәге 222-осн номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Әлеге боерык белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министр урынбасары (комиссия рәисе), Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары), дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторы мөдире, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат (комиссия секретаре), юридик бүлек башлыгы, Министрлыкның башка бүлекчәләрендәге министр билгеләгән дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәтенә бәйле булган фәнни оешмалардан һәм һөнәри белем бирү оешмаларыннан, югары белем бирүче мәгариф оешмаларыннан һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан вәкил (вәкилләр).»;

2.4 пунктта «Килештерү сорау алынган көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

3.11 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;».